**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

11 март 2025 ел № 691

«Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 03 августындагы 2189 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2024 елның 26 декабрендәге 487-ФЗ номерлы Федераль закон, 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон, 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибе турында» Башкарма комитетның 2018 елның 06 августындагы 3794 номерлы карарына таянып

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 03 августындагы 2189 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.9 пунктының 7 пунктчасында «дәүләт җир күзәтчелеге» сүзләрен «федераль дәүләт җир контроле (күзәтчелеге) (алга таба – дәүләт җир күзәтчелеге)» сүзләренә алыштырырга;

1.2. 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 13 пунктчаны өстәргә: «капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше тышкы күренешен килештерү, әгәр мондый килештерү Шәһәр төзелеше кодексының 40_1 статьясында каралган очракта;»;

1.3. 1.4 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлегендә ярдәмче файдаланудагы төзелмәләр һәм корылмалар төзү, аларга кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү буенча ярдәмчесе Н.Ф. Гәрәевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев